КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**КАРАР**

2022 ел, 23 май

г.Казань

№ 482

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2025 елларга «Татарстан Республикасы гражданнарына социаль ярдәм күрсәтү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 23 декабрь, 1023 нче карары белән расланган 2014 – 2025 елларга «Татарстан Республикасы гражданнарына социаль ярдәм күрсәтү» дәүләт программасының 2014 – 2025 елларга «Татарстан Республикасы халкына социаль хезмәт күрсәтүне модернизацияләү һәм үстерү» ярдәмче программасына 5 нче кушымтага үзгәреш кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2025 елларга «Татарстан Республикасы гражданнарына социаль ярдәм күрсәтү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 23 декабрь, 1023 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 22 апрель, 267 нче; 2014 ел, 14 ноябрь, 876 нчы; 2014 ел, 12 декабрь, 977 нче; 2015 ел, 8 апрель, 231 нче; 2015 ел, 19 май, 358 нче; 2015 ел, 1 июнь, 396 нчы; 2015 ел, 16 июнь, 442 нче; 2015 ел, 2 ноябрь, 831 нче; 2016 ел, 24 февраль, 112 нче; 2016 ел, 15 апрель, 225 нче; 2016 ел, 8 май, 288 нче; 2016 ел, 22 июль, 498 нче; 2016 ел, 23 сентябрь, 681 нче; 2016 ел, 30 ноябрь, 884 нче; 2016 ел, 30 декабрь, 1053 нче; 2017 ел, 3 февраль, 59 нчы; 2017 ел, 26 май, 308 нче; 2017 ел, 21 июнь, 411 нче; 2017 ел, 26 июнь, 433 нче; 2017 ел, 10 октябрь, 777 нче; 2017 ел, 15 декабрь, 993 нче; 2017 ел, 29 декабрь, 1077 нче; 2018 ел, 19 гыйнвар, 18 нче; 2018 ел, 14 февраль, 87 нче; 2018 ел, 26 апрель,

285 нче; 2018 ел, 4 май, 318 нче; 2018 ел, 26 июнь, 519 нчы; 2018 ел, 22 сентябрь, 824 нче; 2018 ел, 24 декабрь, 1210 нчы; 2019 ел, 16 гыйнвар, 13 нче; 2019 ел, 2 апрель, 258 нче; 2019 ел, 22 июль, 612 нче; 2019 ел, 22 июль, 612 нче; 2019 ел, 17 сентябрь, 840 нчы; 2019 ел, 28 октябрь, 965 нче; 2019 ел, 12 ноябрь, 1035 нче; 2019 ел, 10 декабрь, 1134 нче; 2020 ел, 3 апрель, 254 нче; 2020 ел, 8 август, 668 нче; 2020 ел, 25 ноябрь, 1064 нче; 2020 ел, 8 декабрь, 1114 нче; 2020 ел, 11 декабрь, 1125 нче; 2020 ел, 18 декабрь, 1151 нче; 2021 ел, 12 март, 125 нче; 2021 ел, 27 март, 175 нче; 2021 ел, 21 июнь, 487 нче; 2021 ел, 6 ноябрь, 1052 нче; 2021 ел, 6 декабрь, 1166 нчы; 2021 ел, 20 декабрь, 1254 нче; 2022 ел, 19 март, 248 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган 2014 – 2025 елларга «Татарстан Республикасы гражданнарына социаль ярдәм күрсәтү» дәүләт программасының 2014 – 2025 елларга «Татарстан Республикасы халкына социаль хезмәт күрсәтүне модернизацияләү һәм үстерү» ярдәмче программасына 5 нче кушымтага, аны яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итеп, үзгәреш кертергә.

Татарстан Республикасы
Премьер–министры А.В.Песошин

2014 – 2025 елларга «Татарстан Республикасы халкына социаль хезмәт күрсәтүне модернизацияләү һәм үстерү» ярдәмче программасына 5 нче кушымта
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2022 ел, 23 май, 482 нче
карары редакциясендә)

2022 елга Татарстан Республикасында өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакыт карау системасын булдыру буенча пилот проектын тормышка ашыру чаралары планы («юл картасы»)

| Т/с | Төп чара исеме / «юл картасы» чарасы | Җаваплы башкаручы | Турыдан-туры көтелә торган нәтиҗә | 2022 елда финанслау, сум | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | гомуми сумма, мең сум | шул исәптән | |
| | | | | | федераль бюджет акчасы, мең сум | Татарстан Республикасы бюджеты акчасы, мең сум |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
| 1. Өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакыт карау системасын булдыруга методик алымнар формалаштыру | | | | | | |
| 1.1. | Карауга мохтаҗ өлкән яшьтәге гражданнарның һәм инвалидларның яшәү шартларына карап һәм карауга мохтаҗлык дәрәҗәләре буенча өйдә озак вакыт карау буенча социаль пакетка керә торган социаль хезмәт күрсәтүләр исемлеген һәм күләмен формалаштыру һәм раслау | ТР Хезмәт министрлыгы* | ТР МК карары | агымдагы финанслау | - | агымдагы финанслау |

---
*Файдаланылган кыскартылмалар исемлеге – 9 нчы биттә.

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1.2. | Сынау үткәрелә торган муниципаль районнарда (шәһәр округларында) апробацияләнүен исәпкә алып, өлкән яшьтәге гражданнарга һәм инвалидларга өйдә социаль хезмәт күрсәтү формасында һәм социаль хезмәт күрсәтүнең ярымстационар формасында күрсәтелә торган социаль хезмәтләр исемлеген актуальләштерү, Татарстан Республикасында хезмәт күрсәтүләр белән тәэмин итүчеләр тарафыннан өйдә социаль хезмәт күрсәтү формасында һәм социаль хезмәт күрсәтүнең ярымстационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибенә үзгәрешләр кертү | ТР Хезмәт министрлыгы | ТР МК карары | агымдагы финанслау | - | агымдагы финанслау |
| 1.3. | Татарстан Республикасында хезмәт күрсәтүләр белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәтләр күрсәтүнең яңартылган тәртибе нигезендә өйдә социаль хезмәт күрсәтү формасында һәм социаль хезмәт күрсәтүнең ярымстационар формасында социаль хезмәт күрсәтүләргә тарифлар әзерләү һәм аларны раслау | ТР Тарифлар буенча дәүләт комитеты, ИСТҮ, ТР Хезмәт министрлыгы | ТР Тарифлар буенча дәүләт комитеты карары | агымдагы финанслау | - | агымдагы финанслау |
| 1.4. | Өйдә социаль хезмәт күрсәтү формасында карауга мохтаҗ гражданның (инвалидның) яшәү шартларына карап һәм карауга мохтаҗ булу дәрәҗәләре буенча озак вакыт карау буенча социаль пакетка бәйле рәвештә, бер социаль хезмәткәргә йөкләнеш нормасын билгеләү | ТР МК, ТР Хезмәт министрлыгы | ТР МК карары | агымдагы финанслау | - | агымдагы финанслау |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1.5. | Озак вакыт карау системасын булдыру кысыларында өлкән яшьтәге гражданнарның һәм инвалидларның социаль хезмәт күрсәтүгә индивидуаль ихтыяҗын һәм карауга билгеләнгән мохтаҗлык дәрәҗәсен билгеләгәндә һәм социаль хезмәтләр күрсәткәндә кулланыла торган документлар формаларын апробацияләү | ТР Хезмәт министрлыгы, СХКУ | документлар формаларын апробацияләү нәтиҗәләре турында Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгына мәгълүмат тапшыру (рәсми сорау буенча) | агымдагы финанслау | - | агымдагы финанслау |
| 1.6. | Карауга мохтаҗлык дәрәҗәсенә карап, өйдә социаль хезмәт күрсәтү формасында социаль хезмәтләр күрсәтүгә вакыт нормасын раслау | ТР Хезмәт министрлыгы | ТР Хезмәт министрлыгы боерыгы | агымдагы финанслау | | агымдагы финанслау |
| 2. Өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакыт карау системасы кысаларында ведомствоара хезмәттәшлек механизмнарын камилләштерү | | | | | | |
| 2.1. | Карау, социаль булышлык күрсәтеп торуга мохтаҗ гражданнар турында мәгълүмат алу, саклау, тапшыру һәм алмашу , озак вакыт карау системасы кысаларында өлкән яшьтәге гражданнарга һәм инвалидларга хезмәтләр күрсәтү мониторингы өчен мәгълүмат системасын камилләштерү | ТР Цифра министрлыгы, ТР Хезмәт министрлыгы, ТР ССМ, «РММАҮ» ДАССУ | гомуми мәгълүмат ресурсы | агымдагы финанслау | - | агымдагы финанслау |
| 2.2. | Медицина оешмалары һәм социаль хезмәт күрсәтү оешмалары арасында озак вакыт карауга мохтаҗ һәм карау хезмәтләре күрсәтелә торган гражданнар турында мәгълүмат алмашу, «Татарстан Республикасы буенча Медик-социаль экспертиза баш бюросы» дәүләт казна учреждениесеннән, Россия Федерациясе Пенсия фондының Татарстан Республикасы буенча бүлеге – дәүләт учреждение- | ТР Хезмәт министрлыгы, ТР ССМ, РФ ПФның ТР буенча бүлеге, МСЭБ | гомуми мәгълүмат ресурсларында озак вакыт карауга мохтаҗ һәм карау хезмәте күрсәтелә торган өлкән яшьтәге гражданнар һәм инвалидлар турында мәгълүмат | агымдагы финанслау | - | агымдагы финанслау |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | сеннән карауга мохтаҗ гражданнар турында мәгълүмат алу, карау хезмәтләре күрсәтелүчеләр турындагы мәгълүматны саклау | | | | | |
| 3. Өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакыт карау системасын булдыруга методик ярдәм күрсәтүне гамәлгә ашыру | | | | | | |
| 3.1. | Өйдә һәм социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтә торган социаль хезмәт күрсәтү оешмаларында «Зәгыйфь өлкән яшьтәге кешеләрне карау. Россия тәкъдимнамәләре» методик тәкъдимнамәләрен гамәлгә кертүдә методик булышлык күрсәтүне гамәлгә ашыру | РРҮ | 45 муниципаль район (шәһәр округы) территориясендә өйдә, социаль хезмәт күрсәтүнең стационар учреждениеләрендә социаль хезмәтләрдән файдаланучы бик хәлсез өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны методик тәкъдимнамәләр нигезендә карауга 100 процент җәлеп итү | агымдагы финанслау | - | агымдагы финанслау |
| 3.2. | «Карау мәктәбе» технологиясен тормышка ашыруга, тернәкләндерүнең техник чаралары прокаты пунктлары эшен оештыруга методик булышлык күрсәтүне гамәлгә ашыру | РРҮ | сынау үткәрелә торган муниципаль районнарда (шәһәр округларында) социаль хезмәт күрсәтү оешмаларына методик булышлык күрсәтүне 100 процент колачлау | агымдагы финанслау | - | агымдагы финанслау |
| 3.3. | ХСХККҮдә, инвалидларны тернәкләндерү үзкләрендә көндезге бүлекләр эшен оештыруга методик булышлык күрсәтүне гамәлгә ашыру | РРҮ | сынау үткәрелә торган муниципаль районнарда (шәһәр округларында) социаль хезмәт күрсәтү оешмаларына методик булышлык күрсәтүне 100 процент колачлау | агымдагы финанслау | - | агымдагы финанслау |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 4. Карауга мохтаҗ өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны ачыклауны һәм аларга карау хезмәтләре күрсәтүне оештыру | | | | | | |
| 4.1. | Озак вакыт карау системасын булдыру буенча пилот проектын тормышка ашыру | ТР Хезмәт министрлыгы, СХКУ | карауга мохтаҗ инвалидларның һәм эшкә сәләтле яшьтәге гражданнарның гомуми санынннан озак вакыт карау системасы кысаларында өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны социаль хезмәт күрсәтүгә 30 процент җәлеп итү | агымдагы финанслау | - | агымдагы финанслау |
| 4.2. | Түбәндәге механизмны эшкәртү: | | | | | |
| | гражданнарның социаль хезмәт күрсәтүгә индивидуаль ихтыяҗларын билгеләү буенча сораштыру анкетасын кулланып, гражданнарның социаль хезмәт күрсәтүгә индивидуаль ихтыяҗын билгеләү һәм аларның мохтаҗлык дәрәҗәсен билгеләү | РРУ, ТСЯО, ХСХККҮ, СХКУ | гражданнарның социаль хезмәт күрсәтүгә индивидуаль ихтыяҗын билгеләү, мохтаҗлык дәрәҗәсен билгеләү, социаль хезмәт күрсәтүнең барлык формаларында озак вакыт карау системасы кысаларында социаль хезмәтләр күрсәтү буенча тәкъдимнәр әзерләү һәм аларны Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгына (рәсми сорау буенча) җибәрү | агымдагы финанслау | - | агымдагы финанслау |
| | социаль хезмәткәрләр тарафыннан карауга мохтаҗ гражданнарга озак вакыт карауның социаль пакетына керә торган карау буенча социаль хезмәтләр күрсәтү | РРУ, ХСХККҮ | | агымдагы финанслау | - | агымдагы финанслау |
| | социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтелә торган социаль хезмәт күрсәтү оешмаларында яшәгән, карауга мохтаҗ булган өлкән яшьтәге гражданнарга һәм инвалидларга социаль хезмәтләр күрсәтү | РРУ, социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтүче СХКУ | | агымдагы финанслау | - | агымдагы финанслау |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | карауга мохтаҗ гражданнарга социаль хезмәт күрсәтүнең ярым стационар формасында озак вакыт карауның социаль пакетына кирә торган карау буенча социаль хезмәтләр күрсәтү тәэмин итүлә торган көндезге бүлекләр эшчәнлеге | РРҮ, составында өлкәннәр һәм инвалидлар өчен көндезге бүлекләре булган СХКУ | | агымдагы финанслау | - | агымдагы финанслау |
| 4.3. | Карауга индивидуаль ихтыяҗны бәяләүне үткәрү, карауның индивидуаль планнарын төзүне һәм тормышка ашыруны һәм социаль хезмәтләр күрсәтүне контрольдә тоту өчен халыкка социаль хезмәт күрсәтү буенча дәүләт комплекслы үзәкләрендә һәм социаль хезмәт күрсәтүнең дәүләт стационар оешмаларында хезмәткәрләр штатын арттыру | ТР Хезмәт министрлыгы, СХКУ | СХКУ штатын карауга индивидуаль ихтыяҗны бәяләүне, карауның индивидуаль планнарын төзүне һәм тормышка ашыруны контрольдә тотуны гамәлгә ашыручы 38 хезмәткәргә арттыру | 21 711,5 | 17 586,3 | 4 125,2 |
| 4.4. | Карауга мохтаҗ өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны проактив ачыклау | ТР Хезмәт министрлыгы, ТР ССМ, ДССУ, СХКУ, РФ ПФның ТР буенча бүлеге, МСЭБ | озак вакыт карауга мохтаҗ өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны проактив ачыклау нәтиҗәләре турында Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгына мәгълүмат бирү (рәсми сорау буенча) | агымдагы финанслау | - | агымдагы финанслау |
| 4.5. | Өйдә социаль хезмәт күрсәтү формасында озак вакыт карау системасын булдыру кысаларында хезмәтләр күрсәтүне оештыру | ХСХККҮ | 4 906 кеше | агымдагы финанслау | - | агымдагы финанслау |
| 5. Өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакыт карау системасы кысаларында яңа технологияләр һәм эш формаларын кертү һәм булганнарын үстерү | | | | | | |
| 5.1. | Дәүләткә карамаган оешмалар тарафыннан хезмәтләр күрсәтүне оештыру | ТР Хезмәт министрлыгы, | дәүләткә карамаган оешмалар тарафыннан күрсәтелә | 51 090,4 | 41 383,2 | 9 707,2 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | дәүләткә карамаган социаль хезмәт күрсәтүләр белән тәэмин итүчеләр | торган «Сиделка» хезмәтенә 211 кешене җәлеп итү | | | |
| 5.2. | Өлкән яшьтәге гражданнар һәм инвалидлар туганнарына өй шартларында карау, техник тернәкләндерү чараларын куллану күнекмәләрен өйрәтү өчен халыкка социаль хезмәт күрсәтү буенча комплексլы үзәкләр тарафыннан «Карау мәктәбе» технологиясен тормышка ашыру | РРУ, ТР Хезмәт министрлыгы, СХКУ | 2022 ел ахырына 300 кешене укуга җәлеп итү | агымдагы финанслау | - | агымдагы финанслау |
| 5.3. | Халыкка социаль хезмәт күрсәтү буенча дәүләт комплекслы үзәкләрендә тернәкләндерүнең техник чаралары прокаты пункты эшләү | ХСХККҮ | 10 пункт | агымдагы финанслау | - | агымдагы финанслау |
| 5.4. | Социаль хезмәт күрсәтү буенча дәүләт оешмалары базасында өлкән яшьтәге гражданнар һәм инвалидлар өчен көндезге бүлекләр эшләү | ХСХККҮ, ИТҮ | 100 кеше | 9 909,3 | 8 026,5 | 1 882,8 |
| 5.5. | Авыл җирендә яшәүче өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны халыкка социаль хезмәт күрсәтү буенча комплекслы үзәкләрнең «Демография» илкүләм проектының «Өлкән буын» федераль проекты кысаларында сатып алынган автотранспорты белән көндезге бүлекләргә (төркемнәргә) алып килү | ХСХККҮ | 8 муниципаль районда авыл җирендә яшәүче өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны ХСХККҮ автотранспорты белән көндезге бүлекләргә (төркемнәргә) алып килү | агымдагы финанслау | - | агымдагы финанслау |
| 5.6. | Социаль хезмәт күрсәтү буенча дәүләт оешмалары базасында көндезге бүлекләр өчен җиһазлар сатып алу | ХСХККҮ | «Казан шәһәре» шәһәр округындагы Халыкка социаль хезмәт күрсәтү буенча комплекслы үзәк» дәүләт | 1 293,9 | 1 048,1 | 245,8 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесенең көндезге бүлеге өчен җиһаз сатып алу | | | |
| 6. Социаль хезмәт күрсәтү оешмалары хезмәткәрләрен әзерләү (аларны һөнәри белем бирү һәм аларны һөнәри укыту) һәм аларга өстәмә һөнәри белем бирү | | | | | | |
| 6.1. | Социаль хезмәт күрсәтү буенча дәүләт оешмалары хезмәткәрләрен түбәндәгеләр буенча укыту программаларын эшләү:<br>гражданнарның социаль хезмәт күрсәтүгә ихтыяҗларын билгеләү буенча сораштыру анкетасын кулланып, гражданнарның социаль хезмәт күрсәтүгә индивидуаль ихтыяҗын билгеләү һәм аларның мохтаҗлык дәрәҗәсен билгеләү;<br>карауга мохтаҗ гражданнарга өйдә социаль хезмәт күрсәтү формасында, социаль хезмәт күрсәтүнең ярым стационар формасында, шулай ук социаль хезмәт күрсәтүнең әлеге формалары берләштерелгән рәвештә карау буенча социаль хезмәтләр күрсәтү;<br>карау буенча индивидуаль план төзү һәм аны тормышка ашыру, карау буенча хезмәтләр күрсәтелгәндә ведомствоара хезмәттәшлекне гамәлгә ашыру | РРУ | социаль хезмәт күрсәтү буенча дәүләт оешмалары хезмәткәрләрен теоретик һәм практик модульләрнең эчтәлеге, сәгатьләр күләме, нисбәте, бәяләү шкаласы һ.б. өлешендә укыту программаларын эшләү | агымдагы финанслау | - | агымдагы финанслау |
| 6.2. | Социаль хезмәт күрсәтү буенча дәүләт оешмалары хезмәткәрләрен түбәндәгеләр буенча укыту: | РРУ | түбәндәгеләрне укытуга җәлеп итү: | агымдагы финанслау | - | агымдагы финанслау |
| | гражданнарның социаль хезмәт күрсәтүгә ихтыяҗларын билгеләү буенча сораштыру анкетасын кулланып, граж- | | дәүләт социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләренең 100 хезмәткәре | агымдагы финанслау | - | агымдагы финанслау |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | даннарның социаль хезмәт күрсәтүгә индивидуаль ихтыяҗын билгеләү һәм аларның мохтаҗлык дәрәҗәсен билгеләү | | | | | |
| | карауга мохтаҗ гражданнарга өйдә социаль хезмәт күрсәтү формасында, социаль хезмәт күрсәтүнең ярым-стационар формасында, шулай ук социаль хезмәт күрсәтүнең әлеге формалары берләштерелгән рәвештә карау буенча социаль хезмәтләр күрсәтү | | дәүләт социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләренең 50 хезмәткәре | | | |
| | карау буенча индивидуаль план төзү һәм аны тормышка ашыру, карау буенча хезмәтләр күрсәтелгәндә ведомствоара хезмәттәшлекне гамәлгә ашыру | | дәүләт социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләренең 100 хезмәткәре | | | |
| 7. Өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны карау буенча күрсәтелә торган хезмәтләрнең сыйфатын контрольдә тоту, пилот проекты нәтиҗәләрен анализлау | | | | | | |
| 7.1. | Озак вакыт карау системасын булдыру кысаларында хезмәт күрсәтелә торган социаль хезмәт күрсәтү оешмалары эшчәнлеген кимендә өч елга бер тапкыр бәйсез бәяләүне үткәрү | ТР Хезмәт министрлыгы каршындагы бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый советлар, ТР ССМ | бәйсез бәяләү уздыру | агымдагы финанслау | - | агымдагы финанслау |
| 7.2. | Өлкән яшьтәге гражданнарга һәм инвалидларга озак вакыт карау системасын булдыру кысаларында күрсәтелә торган хезмәтләрнең үтәлешен мониторинглау | ТР Хезмәт министрлыгы, РРҮ | озак вакыт карау системасы кысаларында күрсәтелә торган хезмәтләрнең сыйфаты буенча хисап | агымдагы финанслау | - | агымдагы финанслау |
| 7.3. | өлкән яшьтәге гражданнарның һәм инвалидларның социаль хезмәт күрсәтүгә индивидуаль ихтыяҗын һәм карауга билгеләнгән мохтаҗлык | РРҮ | социаль хезмәт күрсәтүгә индивидуаль ихтыяҗны һәм карауга билгеләнгән мохтаҗлык дәрәҗәсен | агымдагы финанслау | - | агымдагы финанслау |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | дәрәҗәсен бәяләүне үткәрү сыйфатын контрольдә тотуны оештыру һәм үткәрү | | бәяләүне үткәрү сыйфаты буенча хисап | | | |
| 5 % | Татарстан Республикасында пилот проектын тормышка ашыруны анализлау һәм өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакыт карау системасын алга таба үстерү буенча тәкъдимнәр әзерләү | ТР Хезмәт министрлыгы, ТР ССМ, ТР Цифра министрлыгы | җыелма мәгълүмат-аналитика материалы | агымдагы финанслау | - | агымдагы финанслау |
| Барлыгы | | | | 84 005,1 | 68 044,1 | 15 961,0 |

Файдаланылган кыскартылмалар исемлеге:

МСЭБ – «Татарстан Республикасы буенча медик-социаль экспертиза баш бюросы» федераль дәүләт учреждениесе;
ДАССУ – дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе;
«РММАҮ» ДАССУ – «Республика медицина мәгълүмат-аналитика үзәге» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе;
ДАСХКУ – дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесе;
ДКУ – дәүләт казна учреждениесе;
ДССУ – дәүләт сәламәтлек саклау учреждениесе;
ТР Тарифлар буенча дәүләт комитеты – Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты;
ТР МК – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты;
ХСХККҮ – халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәге;
ТР ССМ – Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы;
ТР Цифра министрлыгы – Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы;
ТР Хезмәт министрлыгы – Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы;
РФ ПФның ТР буенча бүлеге – Россия Федерациясе Пенсия фондының Татарстан Республикасы буенча бүлеге;
РРҮ – «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Республика ресурс үзәге» дәүләт казна учреждениесе;
ТСЯО – территориаль социаль яклау органы;
СХКУ – социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләре;
ИТҮ – инвалидларны тернәкләндерү үзәге;
ИСТҮ – «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасының Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе.